ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮЛСУБИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422669с.Юлсубино,
ул. Татарстан, дом 56а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЮЛСУБИНО АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422669, Юлсубино авылы,
**Татарстан** урамы, 56а нчы йорт

Тел.: (84361) 27542, факс: (84361) 27542, e-mail: Bslt.Rs@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**апреля 2023 года** **с. Юлсубино** **№ 12**

«Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын (урыннарын) булдыру, кулланучыларга аның (аларның) урнашуы турында мәгълүмат бирү турында»

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, “Энергияне сак тоту һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында” 2009 елның 11 ноябрендәгы 261-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнарга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге «Яктырту җайланмалары, электр лампаларын җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китемәслек итеп тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләрен раслау турынд» 2314 номерлы карарына нигезләнеп КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының “Юлсубино авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә терекөмешле лампалар туплану урынын түбәндәгн адреска билгеләргә: Балык Бистәсе районы, Юлсубино авылы, Татарстан урамы, 56 йорт

2. Терекөмешле лампалар кулланучы күпфатирлы йортлар милекчеләре, яллаучылары, кулланучылары өчен эшкәртелгән терекөмешле лампалар туплану урыннары Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 28 декабрендәге

2314 номерлы карары белән расланган “Яктырту җайланмалары, электр лампаларын җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итү, аларны гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә һәм әйләнә-тирә мохиткә зыян китемәслек итеп тиешенчә җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру кагыйдәләре”нең 4 пункты нигезендә билгеләнелә.

3. Күпфатирлы йортларда терегөмөшле лампаларның туплану урыннарын оештыру мөмкин булмаган очракта, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән терекөмөшле лампаларның туплану урыннарын терекөмөшле лампаларны кулланучы күпфатирлы йорт милекчеләре, яллаучылры, биналардан файдаланучылары өчен дип тә билгеләргә.

4. Кулланылган терекөмешле лампаларны беренчел җыю һәм урнаштыру урыннары турында мәгълүматны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында “Авыл җирлекләре” бүлегендә, Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Юлсубино авылы Татарстан урамы, 56а нче йорт адресы буенча урнашкан стендта куярга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

6 Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үз өстемдә калдырам.. Контроль за исполнением настоящего постановления оставляю за собой.

Татарстан Республикасы
Балык –Бистәсе районы
Юлсубино авыл җирлеге башлыгы Х.Х.Гатиятов